**Яңа Әлем балаларбакчасының 2013-2014 уку елына отчёты.**

## I. Татарстан Республикасы Актаныш районы Яңа Әлем балалар бакчасы турында белешмә

*Актаныш муниципаль районы «Яңа Әлем балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү Муниципаль бюджет учреждениесенә 1966 елның 25 ноябрендә нигез салына. 1 төркемдә балалар тәрбияләнә башлый.*
*1982 елда икенче бинага күчә, 2 төркемдә балалар тәрбияләнә, 1987 елдан башлап 3 төркемгә әйләнә. 1997 елның ноябрь аеннан 2 катлы таш бинага күчә. Бүгенге көндә 4 төркемдә 1,5 яшьтән 7 яшькә кадәр 93, бала тәрбияләнә. Аларга 6 педагог, 2 муз. җитәкчесе, 1 өлкән шәфкать туташы, 14 техник хезмәткәр хезмәт куя.*

*Үзенең эшчәнлегендә балалар бакчасы түбәндәге документларга таянып эш алып бара: Устав, РФ нең Конститутциясе, «Белем турындагы законы», ТР ның Конститутциясе,«Белем турындагы законы», «Татарстан Республикасында дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр», «Россия Федерациясе мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе турында положение».*

*Балалар бакчасында белем бирү, мәктәпкәчә белем бирү программасына таянып эшләнә. Бу программаны федераль дәүләт таләпләренә туры китереп, мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасына таянып балалар бакчасы үзе төзи ,эшкәртә һәм куллана. Белем бирү программасы балаларның яшь үзенчәлекләренә, шәхси үсешләренә карап кулланыла. Балаларга тәрбия һәм белем бирү еллык планга, эш программалына, календарь планга,шөгыльләр расписаниесенә карап,төркемнәргә бүлеп үткәрелә. Бакчада балаларга белем белән беррәттән ,төрле үстерү өчендә мөмкинлекләр тудырыла һәм сәләтләрен ачу өчен индивидуаль якын килепөйрәтелә.*

*Балалар бакчада яшь үзенчәлекләренә нигезләнеп төркемнәргә туплана. Төркем бүлмәләре балаларга уйнарга уңайлы булырлык итеп җиһазландырылган.Балаларны тукландыру дәүләтсанэпидкүзәтү оешмасы белән килешеп, балалар үсешенә файдалы булырлык итеп оештырыла. Тукалануның сыйфаты, менюның төрләнеше өчен бакчаның медперсоналы җаваплы булып тора.*

*Бакчада музыкаль тәрбиядә балаларның яшь үзенчәлекләре белән оештырыла ,бәйрәмнәрдә күңелле уздырыла. Бәйрәмнәргә әзерлекне музыка җитәкчеләре тәрбиячеләр белән берлектә оештыра. Балалар төрле конкурсларда катнашалар ,бәйрәм иртәләрендә үзләренең сәләтләрен күрсәтәләр .*

### 1. Гомуми характеристика

Юридик адрес: 423762, ТР, Актаныш районы, Яңа Әлем авылы,
Г.Тукай урамы, 59 йорт. Тел: 88(5552) 6-08-26

а)Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы “Яңа Әлем балалар бакчасы” 2011 елдан башлап мәктәпкәчә белем бирү Муниципаль бюджет учреждениесе булып йөри. Эш режимы : 9 сәгать, эш атнасы 6 көнлек.

б)Белем бирү эшчәнлегенә лицензиясе: серия РТ № 001954, регистрация № 3418, 09 февраль, 2012 дән.

в)Медицина эшчәнлегенә лицензиясе: серия ЛО-01 - 0009972, регистрация № ЛО-16-01-002953, 27 сентябрь 2013 тән

**Балалар бакчасы администрациясе.**

Балалар бакчасы мөдире: Сарварова Гүзәл Рифак кызы, 1 квалификацион категорияле.

# Эчтәлек

1. Мәгълумати белешмә ......................……………………………………1-3

2. Белем бирү учреждениесенең структурасы, эшчәнлек торышы …….....3-9

3. Материаль-техническая база белән тәэмин ителеш…………………......10-15

4. Өстәмә белем бирү чаралары, конкурсларда катнашу …………………15-18

5. Мәктәп белән элемтә ...................………………………………………..18

6. Ата – аналар белән эш ...........................................................…………..18-19

7. Җәмәгатьчелек белән эш ........................................................................19

8. 2014 – 2015 уку елына бурычлар ....................................……………....19

**Педагогик кадрлар турында белешмә**.

Коллектив педагогик кадрлар белән тулысынча тәэмин ителгән: 4 югары, 2 махсус урта белемле педагог һәм 1 махсус урта белемле шәфкать туташы хезмәт куйды.

Аттестация нәтиҗәләре буенча : 2013-2014 уку елында 3 педагог үз гаризалары нигезендә аттестация үтеп I квалификацион категорияле булдылар, шулай итеп, 2014 ел башына 6 тәрбияче дә I квалификацион категорияле булып эшне дәвам иттеләр.

2014-2015 уку елына 1 тәрбияче: Султанова Лилия Хабирян кызы I квалификацион категориягә кабаттан үтү өчен претендент булып тора.

Уку елы башында 2 тәрбияче: Нуриманова И.Ф., Султанова Л.Х., Исламова З.З.лар курс үттеләр. Май аенда тәрбияче: Аглямова Ф.Н.ның ФГОС буенча курс үтүләре күздә тотыла.

**Балалар бакчасы мөдире:Сәрвәрова Гүзәл Рифак кызы** “Балалар бакчасында яңа технологияләр“ проблемасы өстендә эшләде,
эш стажы 15 ел, югары белемле.

**Тәрбияче Исламова Зөлфия Зәет кызы** “Әкиятләр аша балаларның сөйләм телен үстерү” дигән проблема өстендә зурлар төркеме балалары белән эшләде, түгәрәге: “Кечкенә артистлар”, эш стажы 10 ел, махсус урта белемле.

**Тәрбияче Әгъләмова Розалия Хәмит кызы** “Балаларны үз куллары белән матурлык тудырырга өйрәтү” проблемасын алды, һәм мәк. әзерлек төркемендә эшләде, түгәрәге: “Серле кәгазь”, эш стажы 28 ел, югары белемле.

**Тәрбияче Султанова Лилия Хәбирҗан кызы** “Дидактик уеннар аша балаларның мөстәкыйль уен эшчәнлеген үстерү” дигән проблема өстендә 1 кечкенәләр белән эшләде, түгәрәге: эш стажы 26 ел, махсус урта белемле.

**Тәрбияче Закирова Фирүзә Өлфәт кызы** “Дидактик уеннар аша балаларның фикерләвен үстерү” дигән проблема алып уртанчылар төркеме белән эшләде, түгәрәге: “Оригами” – уртанчылар белән, эш стажы 7 ел, югары белемле.

**ТәрбиячеНуриманова Илүзә Флүс кызы** “Дидактик уеннар аша балаларның сөйләм телен үстерү” проблемасын алып ясле төркеме балалары белән эшләде, эш стажы 15 ел, югары белемле.

**Тәрбияче Аглямова Филиза Нәҗип кызы** “Хәрәкәтле уеннар аша балаларда мөстәкыйльлек тәрбияләү” проблемасын алып 2 кечкенәләр төркеме белән эшләде, эш стажы 23 ел, югары белемле.

**Музыка җитәкчесе** (совместитель) **Шарипова Ленара Фавадис кызының** проблемасы : «Балаларның музыкаль сәләтләрен ачуда аларга индивидуаль якын килеп эшләү», түгәрәге: “Чигүле читекләрем”, эш стажы – 10 ел, югары белемле.

Музыка җитәкчесе (совместитель) **Фаррахова Айзәрә Фәнис кызының** проблемасы “Балаларның музыкаль сәләтләрен ачуда аларга индивидуаль якын килеп эшләү”эш стажы – 2 ел, махсус урта белемле.

**Шәфкать туташыИльясова Рәмилә Рәшит кызы** «Балаларның сәламәтлеген традицион булмаган алымнар аша ныгыту» проблемасы өстендә эш алып барды.

Методик эш.

Педагоглар түбәндәгечә үз белемнәрен күтәрделәр:

| № | Тәрбияченең исем-фамилиясе | 2013 – 2014 уку елында ничә РМО да катнашты, курс үтте |
|---|---|---|
| 1 | Аглямова Розалия | 4 РМО |
| 2 | Закирова Фирүзә | Аттестация үтте |
| 3 | Нуриманова Илүзә | Курс, аттестация үтте |
| 4 | Аглямова Филиза | 4 РМО, ФГОС буенча курс үтте |
| 5 | Султанова Лилия | Курс үтте - |
| 6 | Исламова Зөлфия | Курс, аттестация үтте |

Мөдир Г.Р.Сәрвәрова –мөдирләр киңәшмәсендә даими катнашып барды .

**Балалар бакчасында балалар урнашуы**

Бакчага балалар электрон чират һәм ата-аналарның гаризасы нигезендәһәр елда август аенда медицина тикшерүе үтеп килгәннән соң ата-анасы белән килешү төзеп урнаштырыла. Май аенда приказ нигезендә яшь үзенчәлекләре буенча төркемнәргә күчеш ясала. 2013-2014 уку елында балалар бакчасында барлыгы 4 төркемдә 94 бала тәрбияләнде.

"Нарасый" төркеме(ясле)- 22 бала
"Куянкай" төркеме( I кеч.)- 22 бала
"Тиенкәй" төркеме ( 2 кеч.-уртанчы) – 24 бала
"Теремкәй төркеме(зур-мәктәп.әз.) 26 бала
Балалар бакчасыннан 18 бала мәктәпкә укырга бара.

## II. Белем бирү учреждениесенең структурасы, эшчәнлек торышы.

Балаларга эшчәнлекләр алдан расланган расписание нигезендә уздырыла. "Балалар бакчасында тәрбия һәм укыту программасы" мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләүне тагын да камилләштерүгә юнәлтелгән. Ул әхлак, хезмәт тәрбиясе, физик һәм эстетик тәрбия бирүне, яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен искә алып, нәниләрне мәктәпкә әзерләүне күздә тота.
Тәрбия, белем бирү эшендә бертөрлелектән арына барып, заман таләпләренә җавап бирә торган программалар, яңа технологияләр көннән көн күбрәк кулланыла. Шәхесне үстерүгә юнәлтелгән, балаларның фикерләү сәләтен үстерүгә булышлык итүче "Салават күпере", "Үсеш", "Балачак" программаларын, уйлап табу мәсьәләләрен чишү теориясе алымнарын (ТРИЗ), М.Монтессори, Воль-дорф педагогикасы чараларны гамәлгә ашыралар.
Шулай да балалар бакчасы үзенең эшчәнлеген нигездә, "Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы"на (Мәскәү-2005-06) таянып алып бара. Программа безнең алга түбәндәге максатны куя:
"Киләчәк өчен һәрякълап үсеш алган, белемле, рухи һәм физик яктан сәламәт буын тәрбияләү".
2013 - 2014 нче уку елында коллектив "Тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегенең сыйфатын күтәрү" дигән методик тема өстендә эшләде, үз алдына "Җирле мөмкинлекләрдән файдаланып әхлаклы балалар тәрбияләү юлларын камилләштерү" максатын куйды.
Коллектив алдында куелган бурычлар:

1.Шәхескә юнәлтелгән якын килү аша балаларның сәләтләрен ачу, юнәлеш бирү һәм үстерү.
2.Балаларның югары хәрәкәт активлыгын тәэмин итү өчен шартлар тудыру
3. Белем һәм тәрбия процессында яңа ысуллар куллану.

Балалар бакчасы коллективы үз алдына куелган максатны тормышка ашыру өчен балалар, ата-аналар белән план нигезендә системалы эшләде. Һәр башкарылган эшнең нәтиҗәсенә ирешү-үзмаксат булды.

Балалар бакчасында методик эш еллык план нигезендә алып барылды, барлыгы 4 педсовет семинар-практикумнар үткәрелде. Тәрбия – белем программалары, планнары тиешле югарылыкта, таләпләргә туры килерлек итеп эшләнде һәм алып барылды.
Мәктәпкә чыккан укучыларның белем- тәрбиялелекләрен күзәтү максатыннан мәктәптә ачык дәресләрдә катнаштык һәм үзләрен дә ачык шөгыльләргә чакырдык.Укытучылар тарафыннан бакчадан килгән балаларга бирелгән уңай бәя , балаларның мәктәптә югалып калмавы, тәрбиячеләр өчен зур бәхет ул.

**Ясле төркемендә программа үтәлеше 100 %.**
**1 һәм 2 кечкенәләр төркемендә программа үтәлеше 100%**
**Зурлар - уртанчы төркемендә программа үтәлеше 100%**
**Мәктәпкә әзерлек төркемендә программа үтәлеше 100%.**

**Балалар бакчасында эшчәнлекләр ел дәвамында яңа УМК материалларын кулланып алып барылды. Кыскача эшчәнлек белән алдагы слайдлар аша таныша аласыз:**

Ф И З И К тәрбия.

Физик тәрбия бирү буенча еллык эш планы төзедек, планда ата-аналар белән эш тә, балалар белән үткәреләсе чаралар да, спорт бәйрәмнәре дә, күңел ачулар да урын алды. Һәр төркемдә сәламәтләндерү чаралары билгеләнде. Ел дәвамында төрле чыныктыру чараларын үткәреп бардык.

Җәйге спорт бәйрәмен һәм татар халкының милли бәйрәме сабантуй үткәрүгә бакчабызда ныклы әзерлек бара, традициягә әйләнгән әлеге бәйрәмнәрне балалар һәм олылар да һәрвакыт көтеп алалар.

Сәламәтлекне арттыру, хәрәкәтне үстерү, физик әзерлекне тәэмин итү максатыннан балаларга хәрәкәтле уеннар өчен төрле атрибутлар,материаллар әзерләнде, эшләнде. Хәрәкәтле уен өчен “Городки” .”Бадминтон”, “Максатка ыргыт” уеннары, туплар бар. Физкультура шөгыльләре өчен ком капчыкларын яңартып эшләдек. Балаларның төп хәрәкәтләрне үзләштерү күрсәткечләре чыгарылып, диагностик карта алып барылды. Балаларның физик күрсәткечләре һәр айда ата-аналар танышып барырлык итеп эшләп куелды. Һәр төркемдә чыныктыру сукмаклары эшләнеп куелды, ә участокта дару үләннәре зонасы белән янәшә эшләнде.Үлән төнәтмәләре белән тамак чайкау, ноктады массаж, һәр иртәдә суган , сарымсак ашау, йодлы ипи, ”Микройодид” препараты куллану, “С” витаминлы ризыклар бирү, II нче иртәнге ашка җиләк-җимешләр , сөт ризыклары даими булу, менюда һәрвакыт итле, балык, яшелчә ризыкларын нормадагыча куллану, балаларның сәламәтлеге ныклы булуга нигез тудыра.

Бездә үткәрелә торган чыныктыру чаралары:

-сәламәтлек сукмагыннан йөрү;
-көндәлек рационга яшелчәләр,җиләк-җимешләр кертү;
-тамак чайкату;
-сулыш гимнастикасы;
-җәй көне яланаяк йөрү, аякларны җылы комга тыгып утыру;
-үләнчәйләреэчү;
-нокталы массаж;
-һава,су,кояшванналары;
-физкультура шөгыльләре,иртәнге гимнастика;
-витаминнар.

Болар барысы да баланың физик үсешенә уңай йогынты ясый:хәрәкәт активлыгын үстерә,организмдагы матдәләр алмашын яхшырта, ару-талчыгуны бетерә

**2013 елда бала көне күрсәткече түбәндәгечә: бала көне 23060 - 99%**

Ата-аналар өчен “Сәламәтлек” һәм “Әти-әниләргә” стендларына балалар авырулары турында санбюльлетеньнәр чыгарыла: “Гripптан сакланабыз”, “Балаларны тукландыруда витаминнарның роле”, “Балаларда йогышлы авырулар”, “Яз һәм авитаминоз”, “Аю табаны”, “Градусник ниләр сөйли”, “Тамак бакасы”, “Отитлар”, “Холера”, “Энтеробиоз”, “Ревматизм – мәкерле чир”, Балаларның күзләрен саклыйк” һ.б; төрле папкалар һәм ширмалар ясала: “Беренче медицина ярдәме күрсәтә бел”, “Сәламәт булыгыз”, “Яшел аптека”, “Балаларда йогышлы авырулар”, “Аяк астында шифа”, “Бишек”, “Саулыгым – байлыгым”, “Тәмле дә, файдалы да”, “Сәламәт булыйм дисәң”, “Кешенең матурлыгы сәламәтлектә”, “Хәрәкәттә – бәрәкәт” темасына стендлар ясалды.

Дөрес туклану балаларның сәламәтлеген яшхыртуда мөһим роль уйный. **2013 елда бер балага туклану суммасы якынча 37 сум 90 тиен төшә.**

Күрсәткечләрдән күренгәнчә, быелгы уку елында күрсәткечләр яхшыра баруы күзәтелде, узган елгы күрсәткечләр белән чагыштырганда медицина тикшерүе нәтиҗәсендә , сәламәтлек төркеме күрсәткечләре үсә баруын күрсәтте. 2013 – 2014 уку елында Актаныш район үзәк больница врачлары килеп балаларга манту куеп, сәламәтлекләренә медосмотр үткәрделәр, нәтиҗәләр түбәндәгечә булды:

БАЛАЛАРНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК ТӨРКЕМНӘРЕ ТҮБӘНДӘГЕЧӘ:

| **I** | **II** | **III** | **V** |
|---|---|---|---|
| 49 | 43 | 2 - | |

укуелы дәвамында

АВЫРУ БУЕНЧА БЕР БАЛА КАЛДЫРГАН КӨН:
2013ел - 0,5 көн

# 2013- 2014 уку елында үткәрелгән диагностика нәтиҗәләре буенча күрсәткечләр

**ФИЗИК ТӘРБИЯ БИРҮДӘ БАЛАЛАРНЫҢ КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ:**

| нәтиҗә күрсәткечләре | уку елы башы | уку елы азагы |
|---|---|---|
| ТҮБӘН | 10 % | 0 % |
| УРТАЧА | 67 % | 16 % |
| ЮГАРЫ | 23 % | 84 % |

**РУС ТЕЛЕНӘ ӨЙРӘТҮ БУЕНЧА ДИАГНОСТИКА КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ.**

| Нәтиҗә Күрсәткечләре | уку елы башы | уку елы азагы |
|---|---|---|
| ТҮБӘН | 47 % | 0 % |
| УРТАЧА | 33 % | 48 % |
| ЮГАРЫ | 20 % | 52 % |

Бакчабызда рус теле атналыгы уңаеннан план төзелде һәм шул план нигезендә эшчәнлек алып бардык. Шулай ук рус халкының көнкүреше сурәтләнгән почмак булдырдык, шөгыльләрдә, режим моментларында балалар белән эшчәнлек алып барабыз. Рус телендә әкиятләр сәхнәләштерелә, русча җырлар, шигырьләр өйрәттек.
Атнаның һәр шимбә көнен рус теле көне итеп билгеләп, барлык бакча персоналлары да балалар белән рус телендә сөйләшә.

## Математика эшчәнлегенә өйрәтү буенча диагностикак ү р с ә т к е ч л ә р е

| Нәтиҗә күрсәткече | уку елы башы | уку елы азагы |
|---|---|---|
| **түбән** | **24 %** | **0%** |
| **уртача** | **52 %** | **18 %** |
| **югары** | **24 %** | **82 %** |

**БАЛАЛАРНЫҢ СӘНГАТЬ ЭШЧӘНЛЕГЕ БУЕНЧА ДИАГНОСТИКА КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ:**

| Нәтиҗә Күрсәткечләре | уку елы башы | уку елы азагы |
|---|---|---|
| ТҮБӘН | 26 % | 0% |
| УРТАЧА | 60 % | 20 % |
| ЮГАРЫ | 14 % | 80 % |

**БАЛАЛАРНЫ АНА ТЕЛЕНӘ ӨЙРӘТҮ БУЕНЧА ДИАГНОСТИКА КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ.**

| Нәтиҗә Күрсәткечләре | уку елы башы | уку елы азагы |
|---|---|---|
| ТҮБӘН | 18 % | 0 % |
| УРТАЧА | 60 % | 22 % |
| ЮГАРЫ | 22% | 78 % |

**БАЛАЛАРГА ЭКОЛОГИК ТӘРБИЯ БИРҮ БУЕНЧА ДИАГНОСТИКА КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ.**

| Нәтиҗә Күрсәткечләре | уку елы башы | уку елы азагы |
|---|---|---|
| ТҮБӘН | 15 % | 0 % |
| УРТАЧА | 70 % | 17 % |
| ЮГАРЫ | 15 % | 83 % |

**БАЛАЛАРНЫҢ МУЗЫКА ЭШЧӘНЛЕГЕ БУЕНЧА ДИАГНОСТИКА КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ.**

| Нәтиҗә Күрсәткечләре | уку елы башы | уку елы азагы |
|---|---|---|
| ТҮБӘН | 25 % | 0 % |
| УРТАЧА | 75 % | 45 % |
| ЮГАРЫ | 0 % | 55 % |

**ДИАГНОСТИКА НӘТИҖӘЛӘРЕ БУЕНЧА ГОМУМИ КҮРСӘТКЕЧЛӘР:**

| Нәтиҗә Күрсәткечләре | уку елы башы | уку елы азагы |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| ТҮБӘН | 23,6 % | 0 % |
| УРТАЧА | 59,6 % | 26,6 % |
| ЮГАРЫ | 16,8 % | 73,4 % |


**2013 - 2014 уку елында 18 бала укырга керә.**
**Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән үткәрелгән тест нәтиҗәләре буенча белем дәрәҗәләре күрсәткече:**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Иң югары балл** | **-** | **18 - 20 балл** | **-** | **12 бала –** | **66%** |
| **Уртача балл** | **-** | **15 - 16 балл** | **-** | **3 бала –** | **17%** |
| **Түбән балл** | **-** | **7 - 10 балл** | **-** | **3 бала -** | **17%** |

**Гомуми балл - 302**
**1 балага уртача балл- 16**
**өлгереш - 100%**
**сыйфат – 66%**


Яңа Әлем балалар бакчасының 2013 – 2014 уку елында: математика, рус теле, физкультура, ИЗО бүлекләре, сөйләм үстерү, табигать белән таныштыру, музыка, экологик тәрбия эшчәнлекләре буенча чагыштырма **Аналитик** справка .

## Сөйләм үстерү





Балаларның җавапларында , фикерләүләрендә мөстәкыйльлек чагыла. Мәгънәле, аңлаешлы итеп сөйли белергә өйрәнәләр.

## Табигать белән таныштыру.
## Экологик тәрбия.





**Үсеш дәрәҗәләре арта бара. Балаларның тикшерү, тәҗрибә үткәрү нигезендә экологик фикерләү сәләтләре үсә бара.**

Физкультура.





Үсеш дәрәҗәләре арта. Бу инде балаларның физик күрсәткечләренең үсүенә бәйле.

ФЭМП.





**Үсеш дәрәҗәләре арта бара.**

Рус теле.





Саф татар җирлеге булу сәбәпле, балаларны өйрәтүнең күп өлеше балалар бакчасына туры килә. Гаиләдә рус телендә аралашкан бер генә бала бар.

ИЗО.





**Төп сүрәтләү чараларын куллана беләләр. Үсеш дәрәҗәләре үсә бара**


Бала һәм әйләнә-тирә дөнья.




Музыка эшчәнлеге




**ДИАГНОСТИКА НӘТИҖӘЛӘРЕ БУЕНЧА ГОМУМИ КҮРСӘТКЕЧЛӘР:**




**Нәтиҗәләр:**

2013-14уку елында Тәрбия һәм белем бирү программасы үтәлде.

**Тәкъдимнәр:**

Тәрбиячеләргә УМК материалларын эшчәнлекләрдә һәм режим моментларында тагын да активрак кулланырга, җиһазларның калган өлешләрен ломинироватҗ итеп, тышлап бетерергә

# Материаль-техник база белән тәэмин ителеш.

1. Музыка һәм физкультура бүлмәсе;
2. Аудио һәм видео җиһазлар;
3. Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү бүлмәсе;
4. Рус теле почмагы;
5. Экология почмагы;
6. Психик киеренкелекне йомшарту урыны;
7. Музей;
8. Шәфкать туташы бүлмәсе;
9. Методик бүлмә;
10. 4 төркем һәм 4 йокы бүлмәсе;
11. Культура – гигена үстерү бүлмәләре;
12. Ашханә;
13. 4 уен мәйданчыгы;
14. Физкультура мәйданчыгы;
15. Яшелчә бакчасы;
16. Чәчәклек мәйданчыклары;
17. Яшелчә саклау базы;
18. Кер юу һәм җылылык бирү бүлмәләре;
19.

## 2013 -2014 еллар эчендә булган җиһазлар түбәндәгеләре белән тулыландырылды:

Музыка һәм физкультура залы стелаж, микрафоннар, аудиожиһазлар белән җиһазланган, балаларның хәрәкәтен үстерү өчен барлык шартлар тудырылып бүлмә кирәкле 50 төрдәге җиһазлар белән тулыландырылган.




юл йөрү кагыйдәләре бүлмәсе зур һәм йомшак материаллардан тегелгән машиналар, юл йөрү билгеләре төшерелгән киемнәр; рус теленә өйрәтү бүлмәсе курчаклар, методик материаллар белән җиһазланган. Һәр төркем бүлмәсенә өстәл япмалары – 30 штук тегелде,






төрле конкурслар өчен балаларга13 кызга 2 төрдә 26 итәк тектерелде. Санузелларда раковина краннары, 1 туалетка унитаз,спонсорлар ярдәме белән ясле һәм шәфкать туташы бүлмәләренә бойлерлар урнаштырылды, дорожка җәймәләр алынды.2 якның төркем бүлмәләрендә люминесцент лампалар яңартылды. Тышкы 2 як һәм кухня биналарында барысы 4 агач ишек – тимер ишекләргә алыштырылды. Шулай ук мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан бирелгән ноутбук, проектор, методик ярдәмлекләр, аудио һәм видео дисклар, тарату һәм күрсәтмә материаллар да балалар бакчасының материал-техник базасын ныгытуда зур ярдәм булдылар: быелгы уку елында өстәмә 3 ноутбук, 70 штук УМК материаллары кайтты.

Балалар бакчасы ике катлы бинага, авылның урта өлешендә,мәктәп һәм административ биналарга якын урнашкан.Газ белән, үзенең котельнаясы аша җылытыла; су кергән һәм канализация үткәрелгән.Балалар бакчасы интеренет челтәренә тоташтырылган, үзенең сайты бар, ул ел әйләнәсенә яңартылып, тулыландырылып торыла.Төрле эшчәнлекләрне уздыру өчен тиешле теле-, аудио-, видеоаппаратуралар бар.

Кухня, прачка, склад аерым бинада урнашкан. Балалар бакчасы тимер һәм өлешчә агач койма белән уратып алынган. Балалар бакчасының 2 зданиесе дә пожар куркынычсызлыгы сигнализациясе белән тәэмин ителгән, үз каравылчысы да бар.

Балаларга уйнар өчен һәр төркемгә уен участоклары, спорт мәйданчыгы аерым җиһазландырылган. Балаларны азык белән тәэмин итәр өчен җитәрлек күләмдә яшелчә һәм җиләк – җимеш үстерелә, тәҗрибә участоклары да булдырылган. Анда балалар үсемлекләр утыртып, үзләре тәрбияләп үстерәләр. Бакча тирәсендә шулай ук 35 төрле чәчәк үстерелеп, бакчаны гына түгел, бөтен авылны бизәп тора. Быелгысы елда үзебез үстергән чәчәкләрдән тыш чәчәклекләргә тагын бер зур үзгәреш кертелде: авыл советы спонсорлыгы белән 39 төп роза чәчәге, 13 төп яран гөлләр утыртылды. Хәзерге вакытта аларны тәрбияләп үстерү эшләре алып барыла. Зур ярдәме өчен Авыл советы рәисе Анварова Дилбәр Миркасыйм кызына рәхмәтләребезне җиткерәбез.






Балаларга белем һәм тәрбия бирү өчен төркем һәм йокы бүлмәләрендә аларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен искә алып мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 16 штук 3 ярусллы кровать, 25 штук2 урынлык өстәл, 50 урындык, 54 УМК җиһазлары ( алар эчендә 3 ноутбук – һәр төркемдә берәү) кайтартылды.










Рус теле, грамотага өйрәтү эшчәнлекләре өчен ата-аналар ярдәме белән һәр балага эш дәфтәрләре китертелде. Алар белән ел дәвамында эшчәнлекләр алып барылды, ачык ишекләр вакытында әлеге эшләр яктыртылды. Төрле юнәлешләрдә уен эшчәнлеген оештыру өчен уен почмаклары җиһазландырылган, шөгылләрне күп төрле алымнар кулланып үткәрерлек итеп кирәкле материаллар тупланган. Ата-аналар үз теләкләрен белдереп уен өчен җиһазлар кайтартылар, һәр төркем бүлмәсе дә тулыландырылды, баетылды.















Ел дәвамында 3 тапкыр Яр Чаллы курчак театры чакырылды. Балалар аларның эшчәнлегеннән канәгать калды.








Һәр төркем бүлмәсендә магнитофон, ноутбук, методик бүлмәдә компьютер, музыка залында телевизор, мини кинотеатр, музыкаль үзәк,проректор, микрофоннар булдырылган. Балалар белем һәм тәрбия бирү эшендә бу җиһазлар уңышлы кулланыла.

Юл йөрү, рус телепочмагы, эстетик зәвык тәрбияләү урыннарында тиешле белем – тәрбия алу өчен мөмкинлекләр булдырылган: күрсәтмәлелек, зур күләмле уенчыклар, дидактик уеннар, схемалар, җиһазлар, юл билгеләрен өйрәтү өчен треножорлар, магнитлы билгеләр, транспортлар, велосипедлар, хәрәкәтне үстерү өчен макет өстәл, курчаклар, альбомнар, ширмалар һ.б. булдырылган.

Бигрәк тә юл кагыйдәләренә өйрәтү буенча балаларга күп игътибар бирелә. Юл йөрү почмагында һәм участокта балаларны дөрес йөрергә өйрәтүдән тыш,ата-аналарга һәм ЮХИДИ хезмәткәрләренә ачык чаралар еш үткәрелеп,балаларның белемнәре тагын да ныгытылып тора. Бу елдагы уку елында "Яшел Ут" конкурсында катнашып балалар бакчасы тәрбиячесе Султанова Л.Х. 3 урынга һәм ЮХИДИның истәлекле призына да ия була.

Экология зонасына ата – аналар ярдәмендә кечкенә коймалар белән әйләндереп алып чишмә, күл бар, программа буенча гөлләр үстерелә, "Дару үләннәре", " Безнең басуларда игелә" стендлары куелган.

Психик киренкелекне йомшарту урынында зур фонтан ясалган. Балаларга киренкелекне чыгару өчен челтерәп аккан чишмә тавышын тыңлап утырырга йомшак утыргычлар булдырылган, гөлләр үстерелә.

Халкыбызның борыңгыдан ук кулланылган эш коралларын, көндәлек кулланышта булган җиһазларны, һөнәрчеләрнең кул эшләрен үз эченә алган мини музеебыз бар. Аның ярдәмендә балаларга татар халкының яшәеше өйрәтелә.

## Өстәмә белем бирү чаралары, аларны оештыру, конкурсларда катнашу

Бакчада ел дәвамында түбәндәге түгәрәкләр эшләп килде:

1. "Кечкенә артистлар" – җитәкчесе Исламова З.З.
2. "Оригами" – җитәкчесе Ф.Ө.Закирова
3. "Серле кәгазь" – җитәкчесе Р.Х.Әгъләмова.
4. "Чигүле читекләрем" – җитәкчесе Л.Ф.Шарипова
5. "Тылсымлы кашыклар" – җитәкчесе А.Ф.Фаррахова

Тәрбиячеләр түгәрәкне перспектив план нигезендә үткәрделәр. Түгәрәкләргә балалар теләп катнаштылар , өйрәнелгәннәр ата-аналарга, бакчаның бүтән төркем балаларына тәкъдим ителде.

Бакчада сәләтле балалар белән эш оештырылды: балалар белән түгәрәк эшләре, театр куюлар оештырылды, рәсем , шигырь һ.б конкурсларга әзерлек эшләре алып барылды.

"Йолдызлык – 2014" конкурсында бакча балалары бик актив катнаштылар: авыл мәдәният йортында барлыгы 50 бала, район мәдәният йортында йомгаклау концертында 26 бала чыгыш ясады. Нәтиҗәләр: бию коллективы арсында 3 урынга лаек булдылар, диплом һәм бүләк белән, авыл балалар бакчалары арасында гомуми 2 урын һәм бүләк белән бүләкләнделәр. Болар барысы да тәрбияче Аглямова Р.Х., Закирова Ф.Ө. һәм музыка җитәкчеләре Шәрипова Ленара, Фәррахова Айзәрә, ата-аналарның тырыш хезмәт нәтиҗәсе.

# Башка конкурсларда катнашу

Ел дәвамында бакча, район, интернет челтәре аша республика күләмендә уздырылган төрле конкурсларда катнашып призлы урыннар да яуланды. Әлеге эшчәнлекләр таблицада күренә:

| Үткәрелгән вакыты | Нинди конкурс, кайдаүткәрелде | Конкурс исеме | Номинацияләре | Нәтиҗәсе |
|---|---|---|---|---|
| 2013, август | Бөтенроссияиҗади конкурсы | “Талантоха – педагогам и родителям” | “Сценарии детских праздников и мероприятий” номинациясендә тәрбиячеләр Ф.Ө.Закирова һәм И.Ф. Нуриманова – “Костюм” номинациясендә Сарварова А.А.,Лутфуллина З.Р.-Султанова Л.Х.- тәрбияче - | Дипломантла р<br><br>дипломант |
| 2013, сентябрь | Бөтенроссия балалар бәйрәмнәре конкурсы | “Чудеса для Деда Мороза – 2013” | “Чыршыкай” сценариесе белән тәрбиячеләр Ф.Ө. Закирова, И.Ф. Нуриманова, З.З. Исламова | Участие |
| 2013, октябрь | Бөтенроссия дистанцион марафонында, “Весенняя капель” иҗади конкурсы | Уникум “По страницам любимых сказок”, “Экологическая азбука” | “Эти забавные зверюшки” III Бөтенроссия фотоконкурсында балалар белән катнашып, тәрбиячеләр Ф.Ө. Закирова, И.Ф. Нуриманова | Рәхмәт белдерелде |
| 04.01.2014 | Районкүләм | “Зимняя спартакиада работников образования” | - Дартс<br>-<br>- Аркан тарту<br>-<br>- Өстәл теннисы | 2 урын<br><br>2 урын<br><br>3 урын |
| 21.02.2014 | Районкүләм | **“Йолдызлык – 2014”** | - “Халык биюләре”<br><br>- “Хореография-эстрада биюләре<br><br>- **Гомуми авыл балалар бакчалары арасында** | Диплом<br><br>3 урын<br><br>**2 урын** |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.03.2014 | Районкүләм | “Зелёный огонёк-2014” | -“Лучший воспитатель ДОУ по обучению детей ПДД и пропоганде БДД среди родителей Султанова Л.Х. | 3 урын |
| 18.02.14 | Районкүләм | “Актанышский сувенир” | Педагог Аглямова Ф.Н.<br>Педагог Закирова Ф.У.<br>Пед.-гНуриманова И.Ф.<br>Педагог Султанова Л.Х.<br>Педагог Аглямова Р.Х. | Участие<br>Участие<br>Участие<br>Участие<br>Участие |
| 18 Март, 2014 | Районкүләм | “Мир игрушек” | -“Куклы” Закирова Ф.У<br>“Игрушки”Аглямова Ф.<br>“Игрушки-зверюшки” Нуриманова И.Ф.<br>“Куклы” Султанова Л.Х<br>“Куклы” Исламова З.З. | 2 урын<br>Участие<br>Участие<br><br>Участие<br>Участие |
| 05.03.2014 | Районкүләм | “Воспитатель года Республики Татарстан-2014” | Педагог Закирова Ф.У. | Участие |
| 26.03.2014 | Районкүләм | “Кызыклы математика” | -“Төгәллек һәм нәтиҗәлелек” Аглямова Ф.Н.<br>Педагог Аглямова Р.Х. | Җиңүче<br><br>Участие |
| Март, 2014 | III Всеросссийский конкурс | “Мир, в котором я живу!” | “Мои поделки” - Нуриманова И.Ф.<br><br>“Мои поделки” - Султанова Л.Х. | Диплом уастника<br><br>Диплом уастника |
| | Районкүләм | “Спортакиада” (Авыл советы җирлеге өчен) | Аглямова Ф.Н., Ильясова Р.Р. | Участие |
| 29.03.2014 | Районкүләм | “Смотр концерты” | Күмәк халык биюләре: Мари, Мордва, Закарпат белән:<br>Ильясова Р.Р.<br>Мансурова Л.Д.<br>Габидуллина Җ.Ф.<br>Фатихова Г.М. | Авыл советыннан справка – 3 урын өчен |
| 28.03.2014 | Учреждениедә | Смотр-конкурс на лучший уголок природы в Доу | “Лучший уголок природы в Доу”: Закирова Ф.У. һәм Аглямова Р.Х.<br><br>Султанова Л.Х. | 1 урын<br><br>2 урын |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Нуриманова И.Ф. | 2 урын |
| 1.04.2014 | Районкүләм | Смотр-конкурс на лучший уголок природы в Доу | Закирорва Ф.Ө.<br>Аглямова Р.Х. | Участие |
| 16.04.2014 | Районкүләм | “Мини-мисс Актаныш 2014” | - | Диплом участника, приз |
| Апрель, 2014 | Районкүләм | “Новая жизнь традиционных ремесл” | «Бисероплетение»:<br>Исламова З.З.<br><br>Аглямова Ф.Н.<br><br>Мирзасалихова Л.В.<br><br>Султанова Л.Х.<br>Аглямова Р.Х.<br>Закирова Ф.У.<br>Нуриманова И.Ф.<br>Общий коллектив | <br>1 урын<br><br>2 урын<br><br>2 урын<br><br>3 урын<br>Участие<br>Участие<br>Участие<br>Участие |
| Май, 2014 | Районкүләм | “Радуга родного края” | Общий коллектив | Диплом - Лауреат 1- ой степени |

## Мәктәп белән элемтә

Шулай ук ел башында мәктәп белән элемтә планы төзелеп, мәктәп директоры тарафыннан расланып, ел дәвамында элемтә алып барылды. Зарипова Фәйрүзә Нәкиевнаның 1 класста Әлифба бәйрәмендә булдык, эшчәнлеккә анализ ясадык, алга таба эшнең нинди алымнарын кулланганда белем һәм тәрбия бирү эшенең нәтиҗәле булачагын күзалладык. Баян түгәрәгенә йөрүче балалар түгәрәк җитәкчесе Флүн абыйлары белән балалар бакчасына кереп баянга өйрәнү серләре белән таныштырдылар. Балалар белән белем көненнән башланып киткән бәйләнеш ел дәвамында сузылды: мәктәпнең китапханәсенә, ашханәгә,музыкаль залларга экскурсияләргә бардылар, башлангыч класс балалары театры күрсәттеләр, башлангыч класс укытучылары бакчада шөгыльләр карады: мәктәпкә әзерлек төркемендә “Тапкырлар иленә сәяхәт” темасына тәрбияче Аглямова Р.Х. математика эшчәнлеге, “Грамматик сабантуй” темасына грамотага әзерлек эшчәнлекләре. Укыту – тәрбия эшләре буенча урынбасар Р.Н.Фәйзрахманова, башлангыч класс укытучысы Фирая Сарварова, тәрбия эшләре буенча урынбасар Гөлшат Хәмидуллиналар эшчәнлекләргә анализ ясап, алга табаниндирәк юнәлешләрдә эш алып барырга кирәгенә басып ясап, балалар бакчасының педколлективы белән әңгәмә кордылар. Мәктәп белән бакча арасында тыгыз элемтә булдыру – балаларга белем һәм тәрбия бирүдәге туган авырлыкларны җиңел чишәргә ярдәм итә.

## Ата – аналар белән эш

Балалары бакчада тәрбияләнүче гаиләләрнең - 25 гаилә күп балалы гаилә, тулы булмаган гаилә- 4, әтидән аерым яшиләр, әниләре тәрбияли.

26 бала ата-аналар түләвенең 50% ташламасыннан файдалана. Бакча хезмәткәрләре ата-аналар белән һәрвакыт элемтәдә тора. Ел дәвамында 3 гомуми, 16 группа җыелышлары уздырдык. Һәрдаим бәйрәмнәргә чакырып , бергәләп бәйрәмнәр, ачык ишекләр көннәре үткәрдек. Ата-аналар өчен «Сабыйга», «Сәламәтлек», «Бездә бәйрәм», “И, гүзәл туган ягым” стендлары ел дәвамында яңартылып торылды. «Юлда йөри беләбезме?», “Борынгы Казан”, “Тиздән – мәктәпкә!”, “Тукай безнең йөрәкләрдә”, “Бөек Җиңүгә 69 ел!” темаларына папка ширмалар ясадык .Әңгәмә,консультацияләр үткәрдек. Балаларга хезмәт күнекмәләре бирү өчен ата-аналардан эш кораллары ясатып алдык.

«Үз балаңны беләсеңме?», «Мәктәп тормышы» темаларына ата-аналардан анкеталар тутыртып алып гомуми нәтиҗәләр ясадык, кроссвордлар чиштердек. Ата-аналардан алынган анкета нәтиҗәләре - 98% уңай. Ата-аналар тарафыннан бакча эшчәнлеге уңай бәяләнде. Май аенда мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының ата-аналары белән йомгаклау җыелышы үткәрелде, балаларның тест нәтиҗәләре , характеристика белән таныштырдык, киңәшләр бирдек.

Ел дәвамында бакчада еллык план нигезендә, программа буенча һәм үзебезнең бакчаның традициясе нигезендә төрле бәйрәмнәр, шигырь, җыр, спорт конкурслары уздырып килдек. “Белем көне“, “Җәйге спорт бәйрәме”, “Чәчәк бәйрәме”, “Өлкәннәр көне”, “Сөмбелә”, “Аналар көне “,”Каз өмәсе”, “Яңа ел”, авыл халкы өчен клубта искечә Яңа ел бәйрәме , “ Кышкы спорт бәйрәме”, “Әтиләр бәйрәме”.”Гаилә бәйрәме”, “8март - әниләр бәйрәме”, “Нәүрүз килә”, “И туган тел- бөек тел”-Г.Тукай кичәсе,”Кошлар көне”, “Карга боткасы”, “69 ел-Җиңү”- Җиңү бәйрәме, “Саубул бакча” мәктәпкә озату бәйрәме, 1июнь балаларны яклау көненә “ Бәхетле балачак- спорт бәйрәме”, “Сабантуй” бәйрәмнәрен раслатылган, һәр балага бәйрәм хисе тудырырлык, үзе теләп катнашырлык, программалар белән, балаларның сәләтләрен ачу , аны үстерү максатын тормышка ашыру өчен эшләдек.

# Җәмәгатьчелек белән эш

Ел дәвамында балалар белән авыл мәдәния йортында үткән “Өлкәннәр көне”, “Искечә Яңа ел”, “8 март”, “Йолдыздык – 2014”. Район мәдәният йортында 2 тапкыр “Йолдызлык-2014” бәйгесендә катнаштык. Район телевидениесы аша “23 февраль - әтиләр бәйрәме”, “Кошлар көне”бәйрәмнәре, белән чыгышлар ясалды, справкалар алып теркәлде. Китапханәчегә атна саен бакчадагы яңалыклар бирелеп, үз чыгышында алар белән ул радио аша таныштырып барды. Бу эштә тәрбияче Р.Х.Әгъләмованың тырышлыгы зур булды. Авыл музеена, кибет, библиотека, мәктәп, пункт, урманнарга экскурсияләр оештырылды. Мондый урыннарда балалар бик теләп катнаша.

Бөек җиңүнең 69 еллыгына багышлап 8 май көнне авылдагы һәйкәл каршында чыгыш ясадык .

Хәзерге көндә балалар бакчасы чыгарылыш кичәсенә, сабантуй һәм 1 июнь – балаларны яклау көнен уздырырга әзерләнә. Киләчәктә дә балаларга белем һәм тәрбия бирүне сыйфатлы итеп башкарырга кирәк дигән теләктә калабыз.

# 2014– 2015 уку елына бурычлар:

1.**Бакчада балаларга тәрбия һәм белем бирү өчен оптималь шартлар тудыру өстендә эшләү, эш шартларын яхшырту.**

Яңа уку елы башында беренче семинарда тәрбияче, бала һәм ата-аналар арасындагы бәйләнешләрне арттыруның яңача алымнарын куллану турында сөйләшү;

Документлар тутыру, аларның торышына игътибарны арттыру;

**2Балалар бакчасында заманча укыту – тәрбияви тирәлекне яңа мультимедейный технологийяләрне киң куллану ярдәмендә тормышка ашыру.**

- Бакчадагы медиатеканы тулыландыруны дәвам итү;
- Бакчаның сайт эшчәнлеген яхшырту.

**3. Бала тәрбияләүдә гаиләнең ролен арттыру эшен дәвам итү һәм ата-аналарны укыту-тәрбия эшчәнлегенә ныграк тарту.**

- Ата-аналар өчен материаллар туплап, аларны бакча сайтына урнаштыру:
  *1.Бала тормышында гаиләнең әһәмияте.*
  *2.Бала тормышында ата-ана роле.*
  *3. Ата абруе.*
  *4. Эчкече ата- ананың балага йогынтысы.*
- Балаларның сәламәтлекләрен саклау һәм ныгыту өчен шартлар тудыру .